**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава Юлсубинского сельского поселения**
**Рыбно-Слободского муниципального района**
Индекс 422669 с.Юлсубино ул.Татарстан дом 56а телефон

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Юлсубино авыл җирлеге Башлыгы**
индекс 422669 Юлсубино авылы Татарстан ур. 56а йорт
телефон

Тел.: (84361) 30223, факс: (84361) 30223, эл.адрес: Uls.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 07.11.2024 года Юлсубино №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Ямаш авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Ямаш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2024 елның 22 ноябрендэ 10сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
3. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сәләтсез гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан кала ) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау;
2. Су белән тәэмин итү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау;
3. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын(чишмәләрне)төзекләндерү;
4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
5. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

6. Торак пункт территориясен төзекләндерү;
7. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

5. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт, Ямаш авылыХ.Такташ 3в һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

6. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы




Х.Х.Гатиятов